

# Факил Сафин

- Язучы Факил Миңнемөхәммәт улы Сафин (әдәби псевдонимы — Факил Әмәк) 1954 елның 2 гыйнварында Татарстанның Мөслим районы Әмәкәй авылында туган.
- Бишенче класста укыганда шигырьләр, эпиграммалар яза башлый.
- Беренче шигырьләре, урта мәктәпне тәмамлагач, район газетасында басылып чыга.
- Мөслим районы Күбәк урта мәктәбен тәмамлагач, колхозда механизатор булып эшли башлый. Минзәләдә шоферлык һөнәрен үзләштерә.
- 1972—1974 елларда армия сафларында хезмәт итә.

- Армиядән кайту белән районндагы иң зур «Михайловка» совхозында комсомол оешмасы секретаре итеп куела.
- Иске Карамалы мәдәният йорты директоры вазифасын башкара.
- Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый.
- Мәктәптә әдәбият, тарих, хәрби белем нигезләрен укыта.
- 1981 елда Октябрь мәктәбенә  директор итеп чакырып алалар.
- Татар Бүләр урта мәктәбенә директор итеп билгеләнә.

- 1984 елда Чаллы шәһәренә килә.
- КамАЗның автомобильләр җыю заводында, баш конвейерда слесарь-җыючы, бригадир, мастер булып эшли.
- 1988 елда Чаллының Автозавод районы мәгариф бүлеге Ф. Сафинны укыту эшенә чакыртып ала. Ул шәһәрнең 24 нче, 18 нче мәктәпләрендә тарих укыта.
- 1990 елда Факил Сафин, укучыларга Әмәк псевдонимы белән танылган язучы, шагыйрь үз чорында данлыклы «Таң йолдызы» газетасына баш мөхәррир урынбасары булып эшкә килә.
- 1991 елның февралендә Факил КамАЗ радиосының татарча тапшырулар редакциясенә эшкә күчә.

- 1991 елның август аенда Факил Сафин «Аргамак» журналына проза, шигърият бүлегенә мөхәррир итеп чакырыла.
- 1995 елның гыйнварыннан Факил Сафин шәһәр мәгариф идарәсе тәкъдиме белән Чаллы педагогия колледжына әдәбият укытырга китә.
- Чаллыда 1996нчы елда «Фән һәм мәктәп» журналы чыга башлый. Яңа журналны оештыру Факил Сафинга йөкләнә.
- 2000 елның көзендә ул Казанга «Казан утлары» журналына бүлек мөдире итеп эшкә чакырыла.

- Чаллыда 2001нче елда «Мәйдан. Чаллы» дип исемләнгән, әдәби-нәфис, иҗтимагый журнал оештырла. Татарстан Язучылар берлеге җитәкчелеге бу эшкә Факил Сафинны тәкъдим итәләр.
- Ул шулай ук балалар иҗаты түгәрәген оештыручыларның берсе булып та тора. Балалар иҗаты йортында җитәкче булып эшләү дәверендә ул “Көмеш кыңгырау” газетасын чыгару турында уйлый. Хәзер бу газета балаларның яраткан матбугатына әйләнде.

- Факил Сафин — «Соңгы көз» (1989), «Гөлҗиһан» (1994) повестьлары, «Биек тауның башларында» (1999) романы, «Саташып аткан таң» (2002) роман-трилогиясе, күп санлы хикәяләр, Кадыйр Сибгатуллин, Рәшит Бәшәр, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов һ.б. әдипләрнең иҗатлары буенча фәнни эзләнүле, тәнкыйди мәкаләләр; публицистик язмалар, шигырьләр, эпиграмма, пародияләр авторы.

- Ф.Сафин – Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе (2004). Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби премиясе белән бүләкләнә (1999), 1996 елдан – Татарстанның Язучылар берлеге члены; бүгенге көндә Язучылар берлеге рәисенең урынбасары.





# ВИКТОРИНА

- Ф. Сафинның туга н елы, урыны.
- Ф Сафинның беренче шигырьләре кайчан һәм кайда бастырыла.
- Нинди югары уку йортын тәмамлый, кайсы факультетында укый.
- Ничәнче елда Чаллы шәһәренә килә.
- Чаллыга килгән чорда кайда эшли.
- Мәктпләрдә нинди фән укыта.
- Ф.Сафин нинди псевдоним астында әсәрләрен иҗат итә.
- Ф. Сафин Чаллы шәһәрендә чыгучы кайсы газета-журналларда эшли.

- Факил Сафинның мактаулы исемнәре.
- Авторның танылган әсәрләре.